БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
10 ноябрь 2025 ел

**КАРАР**
№ 16

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач районы прокуратурасының 2025 елның 24 сентябрендәге 02-08-02-2025/Прдп362-25-20920011 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Балтач район Советының 2011 елның 21 маендагы 48 номерлы карары (2014елның 19декабрендәге 259 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге 290 номерлы, 2016 елның 11 ноябрендәге 60 номерлы, 2019 елның 31 маендагы 189 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 14 пунктта «исәпкә» сүзләреннән соң «, ә линияле объект исәпкә куелган көннән соң өч ай узгач исәпкә куелган очракта»сүзләрен өстәргә;

1.2. 5.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Автономияле учреждение мөлкәте милекчесе, Россия Федерациясе Гражданлык кодексында каралган очракларда, автономияле учреждение йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылык тота.».

1.3. 5 статьяны түбәндәге эчтәлекле 5.20 пункт белән тулыландырырга:

«5.20. Әгәр балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган муниципаль оешма үзенә беркетелгән милек объектларын арендага бирсә, түләүсез файдалануга тапшырса, гамәлгә куючы тарафыннан «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә, балаларның тормыш эшчәнлеген, белем алуын, үсешен, ялын һәм сәламәтләнүен тәэмин итү, аларга медицина ярдәме күрсәтү, балаларда авыруларны профилактикалау, аларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү өчен әлеге шартнамәне төзү нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелергә тиеш.

Әгәр аларны төзү нәтиҗәләрен бәяләгәннән соң әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән шартларның начараю ихтималы билгеләнсә, аренда шартнамәсе һәм түләүсез файдалану шартнамәсе төзелә алмый.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов